**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында**

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң икс ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Саба районының Түбән Шытсу авылы;

Теләче районының Шармаш авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Питрәч районының Ленино-Кокушкино авылындагы Кыр урамы;

Алексеевск районының Кыркүл авылы янындагы, «Сөт Иле» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Якты Алан» филиалы (Кыркүл бүлекчәсе) тарафыннан мөгезле эре терлек асрау өчен файдаланыла торган территориянең бер өлеше.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 5 августындагы ПУ-706 номерлы Указын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел,07 октябрь
№ПУ-975